ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Сыек көнкүреш калдыклары белән эш итүне хокукый җайга салуны камилләштерү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Сыек көнкүреш калдыклары белән эш итүне хокукый җайга салуны камилләштерү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга җибәрергә.

3. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге мөрәҗәгатен хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2022 елның 18 ноябре
№ 1700-VI ДС

Сыек көнкүреш калдыклары белән эш итүне хокукый җайга салуны камилләштерү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы

МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле Вячеслав Викторович!
Хөрмәтле Михаил Владимирович!

Соңгы берничә ел эчендә Россия законнары җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү мәсьәләләрен җайга салуда зур үзгәрешләр кичерде. Бу өлкәдә нигез булган «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законга 2014 ел ахырында калдыклар белән эш итүнең яңа системасын башлап җибәргән һәм тармак эшен сизелерлек дәрәҗәдә җайга салу мөмкинлеге биргән зур үзгәрешләр кертелде. Әмма хокук куллану тәҗрибәсенең ихтыяҗлары калдыклар белән эш итү өлкәсен җайга салуның яңа рәвешләрен һәм алымнарын эзләүне һәм булганнарын камилләштерүне таләп итә, аерым алганда, бу үзәкләштерелмәгән су җибәрү системасына кагыла.

Үзәкләштерелгән су җибәрү системасына тоташтырылмаган йортларда, шул исәптән күпфатирлыларында, барлыкка килә торган сыек көнкүреш калдыклары (шакшы су чокыры, септиклар һәм башка шундыйлар) белән эш итү тәртибе бүгенге көндә закон дәрәҗәсендә регламентлаштырылмаган диярлек, «сыек көнкүреш (коммуналь) калдыклары» төшенчәсе тәгаен билгеләнмәгән, мондый калдыкларның барлыкка килү һәм туплану нормаларын билгеләү буенча эшләнгән һәм расланган методикалар юк, сыек калдыклар составын билгеләү методикалары юк һәм эшләнмәгән.

Сыек көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәсенең җитәрлек дәрәҗәдә җайга салынмаган булуы әйләнә-тирә мохитнең халәтенә тискәре йогынты ясый һәм халыкның сәламәтлегенә куркыныч тудыра, чөнки алар еш кына су объектларына (буаларга, күлләргә, елгаларга) яисә бу максатлар өчен җайланмаган һәм билгеләнмәгән башка урыннарга ташлана.

Росстат мәгълүматлары буенча, Россиядә торак фондның 65,4 проценты гына үзәкләштерелгән канализация белән җиһазландырылган. Авыл торак пунктларында бу күрсәткеч нибары 18,3 процентка җитә. Татарстан Республикасында бу күрсәткечләр уртача Россиянекеннән аз гына югарырак – тиешенчә 69,8 процент һәм 22,2 процент[1]. Ягъни авыл территорияләренең төп өлеше мондый калдыкларны җыю һәм чыгару махсуслаштырылган транспортта башкарыла торган үзәкләштерелгән су җибәрү системасы белән

[1] Федераль дәүләт статистикасы хезмәте. «2021 ел ахырына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак фондны төзекләндерүнең аерым төрләре белән җиһазлау» рәсми статистика бүлекчәсе, https://rosstat.gov.ru/folder/13706

тәэмин ителмәгән. Үзәкләштерелмәгән су җибәрү системасы хезмәт күрсәтүләренә тарифларны җайга салу законнарда каралмаган.

2021 елның 1 гыйнварына кадәр сыек көнкүреш калдыкларын чыгаруга бәйле мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1997 елның 10 февралендәге 155 номерлы карары белән расланган Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләре белән җайга салынды. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 11 июлендәге 1036 номерлы карары нигезендә әлеге кагыйдәләр үз көчен югалтты.

Шул рәвешле, 2021 елның 1 гыйнварыннан сыек көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясен билгеләүне җайга салу гамәлгә ашырылмый. Бу хезмәт күрсәтүләр өчен сыек көнкүреш калдыкларын җыюны һәм чыгаруны Россия Федерациясе Граждан кодексының 779 статьясы нигезендә түләүле шартнамә буенча башкаручы оешмага түләнә. Сыек көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе шартнамә яклары тарафыннан аны имзалаганда ирекле итеп билгеләнә. Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару тарифларының җайга салынмавы шартларында гражданнарның әлеге хезмәт күрсәтүләр өчен ирекле бәяләр буенча түләргә мәҗбүр булуы социаль тигезсезлеккә китерә.

Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сыек көнкүреш (коммуналь) калдыклары белән эш итүне, алар белән эш итүнең тулы циклын (тариф билгеләү, транспортлау, чистарту, утильләштерү) формалаштырып, хокукый җайга салуны камилләштерү һәм үзәкләштерелмәгән су җибәрү системасы хезмәт күрсәтүләренә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салуны кертү мәсьәләләрен карау үтенече белән Сезгә мөрәҗәгать итә.